ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл
җирлеге Советы

422740, ТР Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1/1
тел. 36-3-39

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Кубянского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422740, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Кубян, улица Х.Такташа, 1/1
тел. 36-3-39

# КАРАР

02 октябрь 2017 ел. № 57

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күәм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 16 номерлы Күәм авыл башкарма комитеты карары, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 56 номерлы Күәм авыл җирлеге Советының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советы карар **бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Күәм авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:
- төзелеш материаллары сатып алу, Үртәм авылының урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү;

2. Әйшияз, Дусым авылларында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү һәм ремонтлау;

3. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
- Җилгелде авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу,
- Күәм авылы зираты территориясен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

4. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Каенсар авылы урамнарын яктырту челтәрләрен ремонтлау;

- Күәм авылы территориясен чистарту.

ӘЙЕ ЮК»

3. Күәм авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Күәм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Әтнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.